| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОКУВАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ КУАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>15 октябрь 2020 ел | КАРАР<br>№ 10 |

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 2 октябрендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 2 октябрендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулылаандырырга:

«инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
совет рәисе

И.Н.Сушкова